ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЗЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.22,
с. Азеево,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АКЪЯР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 22,
Акъяр авылы,423190

тел.: (8- 84348) 3-71-31, факс: (8-84348) 3-71-61 Azeev.Nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

16 нче май 2024 ел

№ 10

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында»29.04.2019 № 19 карарына үзгәрешләр кертү хакында.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «2024 елның 1 июленнән бюджет өлкәсе хезмәткәренең хезмәт хакын арттыру турында» 18.04.2024 ел, №03-12/2677 рекомендация хаты нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерының социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Акъяр авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Башкарма комитетының карары белән (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Башкарма комитетының 29.04.2019 № 19 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба – нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерларның вазифа хезмәт хакы түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Вазифа | Авыл җирлеге башкарма комитетында халык саны 3,5 мең кешегә кадәр булган вазифа хезмәт хакы |
|---|---|
| Баш бухгалтер | 23 700,0 |

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Башкарма комитетының штат расписаниесенә кертү шарты булып муниципаль берәмлек халкының саны 3,5 меңнән артык кеше тора.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында»: https://pravo.tatarstan.ru һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга

3. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Акъяр авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Д.С.Гайнуллин